КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 апрель № 237

г. Казань

Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен өстәмә акчалата түләүләр турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибен һәм шартларын;

Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибен.

2. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү турындагы шартнамәнең бертип формасын билгеләнгән тәртиптә эшләргә һәм 2015 елның 15 апреленә кадәр расларга.

3. Бу карар 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\237.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 10 апрель, 237 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары

1. Бу Тәртип  Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә (алга таба – машина йөртүчеләр) эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру механизмын билгели.

2. Машина йөртүчеләргә эшчәнлекләре үзенчәлеге өчен айлык акчалата түләүләр айга өч мең сум күләмендә билгеләнә һәм бу вазыйфа буенча эш күләменә пропорциональ рәвештә гамәлгә ашырыла (1,0 ставка, 0,75 ставка, 0,5 ставка, 0,25 ставка).

Машина йөртүче тулы булмаган ай эшләгән очракта (ялда, укуда булган чор, вакытлыча хезмәткә яраксыз булган чор, шулай ук эштә булмаган башка чорлар), эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен акчалата түләү законнар нигезендә фактта эшләгән вакыт өчен гамәлгә ашырыла.

3. Йөклелек һәм бала табу буенча ялда, бала карау буенча ялда булган хезмәткәрләргә эшчәнлек үзенчәлеге өчен акчалата түләү бирелми.

4. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен акчалата түләүләр уртача эш хакын исәпләп чыгарганда машина йөртүчеләргә Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән гарантияләрне бирү максатында исәпкә алына.

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 10 апрель, 237 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле булган чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин итү
тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә (алга таба – машина йөртүчеләр) эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү һәм аны тоту механизмын билгели.

2. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы агымдагы айның 25 енә кадәр бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Фонд бюджетына соңгысының бюджет гаризалары нигезендә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бюджетара трансфертлар бирә.

3. Фонд машина йөртүчеләргә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү турында медицина оешмалары белән Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгыраслаган бертип форма нигезендә шартнамәләр төзи.

4. Фонд медицина оешмалары белән төзелгән шартнамәләр һәм соңгыларының бюджет гаризалары нигезендә медицина оешмаларына мәҗбүри медицина иминияте акчасы белән операцияләрне исәпкә алу өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси исәпләргә агымдагы айның 30 ына кадәр акча күчерә.

5. Медицина оешмалары җитәкчеләре хисап аеннан соң килүче айның 5 еннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына машина йөртүчеләр регистрларын кертә.

6. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы машина йөртүчеләрнең төбәк регистрын алып баруны гамәлгә ашыра һәм хисап аеннан соң килүче айның 10 сыннан да соңга калмыйча әлеге регистрны Фондка кертә.

7. Медицина оешмалары җитәкчеләре ай саен, 15 еннән дә соңга калмыйча, машина йөртүчеләргә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен агымдагы айда акча бирүгә бюджет гаризасын һәм агымдагы

айда машина йөртүчеләргә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләр гамәлгә ашыруга җибәрелгән акчаны тоту турында Фондка Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча хисап кертә.

Акча календарь аенда файдаланылмый калса, медицина оешмасы калган акчаны 10 көн эчендә Фондка кире кайтара.

8. Фонд ай саен:

агымдагы айның 20 сеннән дә соңга калмыйча машина йөртүчеләргә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле акча күләме турында Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына бюджет гаризасын кертә;

хисап аеннан соң килүче айның 20 сеннән дә соңга калмыйча машина йөртүчеләргә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләр гамәлгә ашыруга җибәрелгән акчаның керүе һәм аны тоту турында Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына хисап бирә.

9. Бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

10. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы, Фонд һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы машина йөртүчеләргә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен медицина оешмаларына кергән акчадан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны тәэмин итә.

F:\KARAR\2015\237-2.docx